**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының**
**Азнакай шәһәр тибындагы бистә Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.б. № 14 «05» сентябрь 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәренә юбилей уңаеннан бирелә торган өстәмә гарантия турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 42 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Актүбә шәһәр тибындагы бистә » муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының**
**Азнакай шәһәр тибындагы бистә Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә » муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәренә юбилей уңаеннан бирелә торган өстәмә гарантия турында кушымта итеп бирелә торган нигезләмәне расларга.
2. 2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2016 елның 13 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.А. Галиева

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының 2017 елның " 05 " сентябрендәге 14 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә » муниципаль берәмлегенең юбилее уңаеннан Муниципаль хезмәткәргә бирелә торган өстәмә гарантия турында Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Өстәмә социаль һәм башка бер тапкыр бирелә торган гарантияләр юбилей датасына 55 яшь - хатын-кызларга һәм 60 яшь - ир-атларга җиткәндә, әгәр бу датага ул муниципаль хезмәт вазифасын биләгән булса, айлык хезмәт хакы күләмендә, әлеге Положениенең 1.2. пункты исәпкә алынып, муниципаль хезмәткәргә түләнә.

1.2. Өстәмә социаль һәм башка гарантияләр муниципаль хезмәт стажына бәйле рәвештә матди ярдәм рәвешендә түбәндәге күләмдә түләнә:

| Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең гомуми стажы | 55 яшькә җиткән хатын-кызларга һәм 60 яшькә җиткән ир-атларга өстәмә социаль һәм башка гарантияләрнең күләме |
|---|---|
| 10 елдан артык | 2 |
| 15 елдан артык | 5 |
| 20 елдан артык | 7 |
| 25 елдан артык һәм күбрәк | 10 |

1.3. Муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт стажы 55 яшькә җиткән көнгә - хатын-кызларга һәм 60 яшькә - ир-атларга билгеләнә. Әгәр 55 яшькә җиткән көнгә хатын-кызларга һәм 60 яшькә ир-атларга өстәмә социаль һәм башка гарантияләр алынмаган булса, түләү Россия Федерациясе Законы белән каралган пенсия яшенә җиткәндә, ләкин әлеге Положениенең 1.4. пункты исәпкә алынып башкарыла.

1.4. Өстәмә социаль һәм башка гарантияләр бер тапкыр түләнә. Матди ярдәм рәвешендәге өстәмә социаль һәм башка гарантияләр кабат түләнми.

1.5. Өстәмә социаль һәм башка гарантияләрне түләү турында карар җирле үзидарә органы җитәкчесе - эш бирүче вәкиле (эш бирүче) тарафыннан кабул ителә һәм хокукый акт белән рәсмиләштерелә.

1.6. Өстәмә социаль һәм башка гарантияләрне түләү өчен җирле үзидарә органы 55 яшькә җиткән көннән соң 3 календарь көн эчендә хатын-кызларга һәм 60 яшькә ир-атларга яки 1.3. пунктында күрсәтелгән башка чорда Азнакай муниципаль районының МКУ «Финанс – бюджет палатасы»на түбәндәге документларны тапшыра:

1.6.1. муниципаль хезмәткәрнең вазифа оклады һәм айлык хезмәт хакы турында белешмә;

1.6.2. җитәкче һәм кадрлар хезмәте органы тарафыннан расланган муниципаль хезмәттә эш стажы турында белешмә;

1.6.3. хезмәт кенәгәсе һәм хәрби билетның кадрлар хезмәте органы тарафыннан расланган күчермәләре;

1.7. Җирле үзидарә органы, әлеге Положениенең 1.6. пунктында каралган документлар тапшырылганнан соң 1 ай эчендә, хезмәт хакы фонды исәбеннән матди ярдәм рәвешендә өстәмә социаль һәм башка гарантияләр түләргә бурычлы.